АГЕНТСТВО
ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ
АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.09.2022 № 52

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 15.02.16 № 13-2/2лс боерыгы белән расланган дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының Комиссиясе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 25 апрелендәге 232 номерлы РФ Президенты Указы һәм «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль законның 26 статьясына һәм «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 6 мартындагы 44-ФЗ номерлы Федераль закон басылуга бәйле рәвештә

БОЕРУ

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 15.02.16 № 13-2/2лс боерыгы белән расланган дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының Комиссиясе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктының «а» пунктчасында «юридик бүлек» сүзләрен «хокукый һәм кадрлар белән тәэмин итү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктының «а» пунктчасының беренче абзацына «(шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып)» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктының «г» пунктчасына «тикшерү материалларын» сүзләреннән соң «(шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып)» сүзләрен өстәргә;

3.2 пунктында «мотивацияләнгән йомгаклау» сүзләреннән соң «(шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып)» сүзләрен өстәргә;

3.4 пунктында «йомгаклау» сүзләреннән соң «(шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып)» сүзләрен

өстәргә;

3.4.1 пунктында «йомгаклау» сүзеннән соң «(шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып)» сүзләрен өстәргә;

3.4.2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Мотивацияле йомгаклау» әзерләгәндә, шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча Агентлыкның коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе биргән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә, аннан язмача аңлатмалар алырга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен Агентлык дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга үтенечләр җибәрә ала, шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып. Мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, йомгаклау һәм шулай ук башка материаллар хәбәр яисә мөрәҗәгать алынганнан соң җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Сорау җибәрелгән очракта, шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, йомгаклау һәм шулай ук башка материаллар комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки хәбәрнамә кергән көннән 45 көн эчендә тапшырыла. Әлеге срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артыграк түгел.».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче                                                                 Т.И. Миңнуллина